**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 апрель № 225

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 сентябрь, 630 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алу өчен Татарстан Республикасыннан гомуми гаризага кертелергә тиешле чараларны сайлап алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алу өчен Татарстан Республикасыннан гомуми гаризага кертелергә тиешле чараларны сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 4 сентябрь, 630 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 549 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт

программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы кысаларында Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү буенча комплекслы инвестицион проект чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидия алу өчен Татарстан Республикасыннан гомуми гаризага кертелергә тиешле чараларны сайлап алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

20 нче пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) махсуслаштырылган оешма урнаштырыла торган бинага милек хокукын раслый торган күчемсез мөлкәт объектына хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамәнең яки Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәнең күчермәсе яисә әлеге бинаны арендалау шартнамәсе күчермәсе;»;

22 нче пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың өстәмә һөнәри белем бирү программасы буенча яки аңа охшаш тематикадагы өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча яңадан һөнәри әзерләү һәм квалификация күтәрү өлкәсендә тәҗрибәсе яки квалификацияле укытучылар составы булу;»;

24 нче пунктның «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың өстәмә һөнәри белем бирү программасы буенча яки аңа охшаш тематикадагы өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча яңадан һөнәри әзерләү һәм квалификация күтәрү өлкәсендә тәҗрибәсе яки квалификацияле укытучылар составы булуын раслый торган документлар күчермәләре;»;

37 нче пунктның «г» пунктчасында «инжиниринг үзәге урнаштырыла торган... (биналар), һәм (яки) тиешле күчемсез мөлкәт объектын арендалау турында шартнамәләр күчермәләре» сүзләрен «яки инжиниринг үзәге урнаштырыла торган биналарга милек хокукын раслый торган Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр, һәм (яки) әлеге биналарны арендалау шартнамәләре күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

40 нчы пунктның «ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) машиналар һәм җиһазлар урнаштырыла торган бинага милек хокукын раслый торган күчемсез мөлкәт объектына хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамәнең яки Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәнең күчермәсе яисә әлеге бинаны арендалау шартнамәсе күчермәсе;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\225.docx